УДК 81′373

***Р.К. Сәгъдиева***

# СҮЗЛӘР АРАСЫНДАГЫ ТӨГӘЛЛӘҮЛЕ МӨНӘСӘБӘТНЕ БЕЛДЕРӘ ТОРГАН ЧАРА БУЛАРАК СҮЗЛӘРНЕҢ ЯНӘШӘ ТОРУЛАРЫ

В образовании связи слов, выступающих в конкретизирующее отношение в татарском языке, как правило, участвует несколько средств связи вместе. Соседство слов, как средство связи, также осуществляет связь слов не один, а вместе с лексическим значением, интонацией, иногда порядком слов и с аффиксом притяжательности. В данной статье исследуется соседство слов как средство связи конкретизирующего отношения в татарском языке, выявлены смысловые оттенки и значения.

**Ключевые слова:** конкретизирующее отношение, соседство слов, средство связи, господствующее слово, зависимое слово.

In the formation of the connection of words, acting in a concretizing relation in the Tatar language, as a rule, several means of communication are involved together. The neighborhood of words, as a means of communication, also carries out the connection of words not one, but together with the lexical meaning, intonation, sometimes the order of words and with the affix of possessiveness. This article examines the neighborhood of words as a means of communication concretizing relations in the Tatar language, identifies semantic shades and meanings.

**Keywords:** concretizing relation, neighborhood of words, means of communication, dominant word, dependent word.

Сөйләмдә сүзләр бер берсенә бәйләнеп килә. Сүзләр бәйләнеше эчтәлектән һәм формадан гыйбарәт. Эчтәлек булып – алар арасындагы төрле мәгънә мөнәсәбәтләре, ә форма булып төшенчәләрне бәйли торган чаралар тора. Сөйләмне оештыра торган төп синтаксик берәмлек – җөмлә – сүзләрнең ияртүле юл белән бәйләнешкә керүеннән хасил була.

Ияртүле бәйләнеш – сөйләм оештыруда катнаша торган сүзләр арасындагы ияртүле мөнәсәбәтне махсус тел чаралары, ягъни төшенчәләрне бәйли торган чаралар белән белдерү ул. Ияручe белән ияртүче компонент арасындагы мөнәсәбәт мәгънәви мөнәсәбәт дип тә йөртелә. Шуңа нигезләнеп, ияртүле бәйләнешнең өч төрле мәгънә мөнәсәбәтен аерып чыгаралар: хәбәрлекле, ачыклаулы (төгәлләүле) һәм аныклаулы [Алпаров, 1945, б. 213; Зәкиев, 1958, б. 17; Сафиуллина, Ибраһимов, 1994, б. 11].

Ияртүле бәйләнешнең бер төре булган төгәлләүле мөнәсәбәт синтаксик күренешләрнең иң бае, иң күләмлесе, чөнки ул күптөрле чаралар ярдәмендә белдерелә [Сагдиева, 2000, с. 23]. Сөйләмдә әлеге бәйләүче чаралар, гадәттә, бер-берсе белән үрелеп бара. Мәсәлән,

*Һавада кошлар оча* җөмләсендә *һавада очу* берәмлеге тәгәлләүле мөнәсәбәттә килә. Әлбәттә, анализ вакытында *һава* һәм *очу* сүзләре урын-вакыт килеше кушымчасы *-да* ярдәмендә бәйләнгәннәр диелә. Әмма әлеге ике төшенчә шул ук вакытта үзара лексик мәгънә ягыннан да бәйләнгән. Янәшә тору чарасы да башка чаралар, ягъни лексик мәгънә, сүз тәртибе, интонация белән бергә кулланыла. Еш кына тартым кушымчасы да өстәлә. Әлеге хезмәт исә янәшә тору чарасы хакында. Әлеге чара кайсы сүз төркемнәре арасында бәйләүче чара вазифасын башкара, бу очракта нинди мәгънә мөнәсәбәтләре хасил була? Мисаллар ярдәмендә шуңа күзәтү ясарбыз.

Янәшә тору чарасы ярдәмендә исем белән фигыль арасында тәгәлләүле бәйләнеш оеша ала. Бу вакытта баш килештәге исем, һичшиксез, фигыль белән янәшә торырга тиеш. Әлеге очракта түбәндәге мәгънә мөнәсәбәтләре хасил була.

Иярүче исем иярткүче фигыль белән янәшә торганда, туры объектны белдерә: *Авылдашлар күктә* ***печән чаба****, ялт-йолт килә үткер чалгылары* (Л. Зөлкарнәй).

Иярүче исем хәрәкәт фигыле белән белдерелгән процессның үтәлү урынын: *Абау, әллә инде* ***су кергәндә*** *телен чуртан балык тешләп алган?* (Г. Гобәй) яисә вакытын ачыклый ала: ***Кич уңмаган иртә уңмас****, ди шул халык* (Т. Галиуллин).

Иярүче исем процесс үтәлүенең вакыт яки пространство ягыннан күләм-чамасын, дәрәҗәсен белдерә: *Шушы хәбәрне ишетүгә йөрәге бөтәнчә җилкенә башлаган Сөләйман карт Шәкүр солдатны* ***көн көтте, төн көтте****, [...], Шәкүрнең шәүләсе күренмәде* (А. Гыйләҗев). Бик еш кына исемнәр сан белән тәгәлләндерелә (*биш ел уку, алты чакрым узу*), һәм нәтиҗәдә катлаулы тәгәлләүле мөнәсәбәт хасил була.

Иярүче исем иярткүче хәрәкәт фигыле белән бирелгән эш-хәлнең коралын ачыклап килә: *Балалар таудан* ***чана шуалар****.* Ләкин татар телендә андый тезмәләр әкренләп идиоматик тезмәгә әйләнә баралар.

Сан сүз төркеме белән фигыль сүз төркеме янәшә килеп, тәгәлләүле мөнәсәбәт хасил булганда, иярткүче фигыль белән белдерелгән эшнең саны, күләме конкретлаштырыла: ***Бер күрде****, аннары ничектер бик табигый рәвештә танышып та киттеләр, сөйләшә, көлешә, уйный-шаяра да башладылар* (Ә. Еники).

Сөйләмдә еш кына рәвеш белән фигыль арасындагы тәгәлләүле мөнәсәбәтне дә янәшә тору чарасы белдерә. Бу очракта иярүче рәвеш иярткүче компонент аша белдерелгән процессның үтәлү ысулын ачыклап килә ала: *Зарифуллин яланбаш тора иде, нindiдер* ***аңсыз хәрәкәт ясап****, башыннан бүрек эзләде* (М. Мәһдиев).

Күләм-чама рәвеше фигыль белән янәшә килеп, тәгәлләүле мөнәсәбәт барлыкка килгәндә, эшнең күләм-чамасы тәгаенләнә: ***Озак та үтми****, ул үзенең өстенлеген күрсәтүдә шул дәрәҗәгә барып җитте ки, миңа хәтта әти-әнием алдында шелтә ясый торган булды* (Ә. Еники).

Ияручe вакыт рәвеше эш-хәрәкәтнең үтәлү вакытын төгәлләндереп килә ала: ***Иртә торып, соң ятарга*** *өйрәнгән, иркә шәһәр тормышы белән бозылмаган авыл егетенә тәртипкә күнегү әллә ни кыен булмады* (Т. Галиуллин).

Урын рәвеше дә фигыль белән янәшә килә, һәм бу очракта процессның үтәлү урыны ачыклана: *Сүзләр якын иде, күңелләр* ***ерак булды*** (Ш. Галиев).

Кабатлауны белдерә торган рәвешләр (*тагын, кабат, яңадан*) фигыльләр белән янәшә килеп, төгәлләүле мөнәсәбәт хасил итәләр һәм кайчандыр башкарылган процессның янә кабатлануын аңлаталар: *Алай гына да түгел, мин аның* ***яңадан кабынуын*** *тели идем, киләчәгем хакына, әти-әнием хакына ихлас күңелдән тели идем* (Ә. Еники).

Сәбәп һәм максат рәвешләре дә фигыль сүз төркеме белән янәшә килә һәм төгәлләүле мөнәсәбәт хасил итә. Нәтиҗәдә, процесс үтәлүнең максаты яисә сәбәбе тәгаенләнә: *«Кемне, нәрсәне?» – дигән булдым мин,* ***юри аңламаган*** *булып* (Ә. Еники).

Бернинди кушымчасыз, бәйлек һәм бәйлек сүзләрдән башка, ә янәшә тору чарасы ярдәмендә генә исемнәр арасында да төгәлләүле мөнәсәбәт барлыкка килә, һәм түбәндәге мәгънәләр ачыклана.

Теге яки бу әйбер үзе ясалган материалы аша төгәлләндерелә: *Манарасы кыйшайган мәчетнең* ***калай гөмбәзендә, җиз аенда*** *кояш уйный, кояшлы урамнар, салам түбәле, кыйшык-мыйшык ызбалар, ара-тирә калай яки агач түбәле төзек йортлар гамьсез тынлыкта рәхәт черем итәләр кебек* (Г. Гобәй).

Ияручe компонент иярүче исем белән бирелгән затның һөнәрен белдерә, ягъни зат үзенең профессиясе аша ачыклана: *Мин колхозның идарәсенә – авылдан сөрелгән* ***кибетче Сәгъдиләр*** *өенең урам башына барып кердем* (Ә. Еники).

Кайбер очракларда исемнәр арасында төгәлләүле мөнәсәбәт хасил булганда, иярүче исем үзе сан аша ачыкланып килергә мөмкин (*бер пот он, ике чиләк су, биш чакрым юл*), һәм, нәтиҗәдә, катлаулы сүзтезмә оеша: *Бәдретдин үзенең сандыгыннан* ***бер-ике уч шикәр*** *алып, шушы ашъяулык уртасына салды* (Ә. Еники).

Ияртүче компонент белән бирелгән әйбер яки зат иярүче исем аша белдерелгән әйбергә яки затка охшатыла, йә аның белән чагыштырыла. Әгәр иярүче сүз чагыштыруның объектын белдерсә, ияртүче исем чагыштыруның субъектын атый. Бу төр төгәлләүле мөнәсәбәт сөйләмгә сәнгатьлелек өсти. Әлеге очракта да төрле мәгънә төсмерләре чагылыш таба: а) затлар яисә әйберләр билгеләре, характерлары ягыннан охшатыла: *Мин югында* ***пәри егетләр*** *урламасын үзеңне* (М. Мәһдиев); ә) әйберләр үзара күләмнәре, саннары ягыннан чагыштырыла: *Гомер буе язып,* ***тау кулъязма*** *җыйган һәвәскәрләр...* (Т. Галиуллин); б) әйберләр үзләренең формалары аша тәңгәлләштерелә: *Ап-ак булып чуарланып тора – игенченең* ***борчак-борчак тирләре*** *әрәм тәгәрәп ята* (Ш. Галиев). Бу очракта янәшә тору чарасы белән бергә кабатлану чарасы да файдаланыла.

Янәшә тору чарасы – сыйфат белән исем арасындагы төгәлләүле мөнәсәбәтне белдерә торган чара да. Бу очракта да ияртүче компонент ияртүче компонентны төрле яктан ачыклап килә: а) ияртүче исем белән бирелгән күренешнең, әйбернең төсен белдерә: ***Зәңгәр күктә ак болытлар*** *туктап калган* (Ш. Галиев); ә) әйбернең күләм-чамасын ачыклый: ***Биек яр*** *буйларында агач кәүсәсендәге еллык боҗрасыдай түшәлгән гасырлар катламын киселештә күрергә була* (Ш. Галиев); б) күренешне, әйберне образы, формасы ягыннан төгәлләп килә: *Куаклык артындагы* ***түгәрәк күл*** *дә уянып килә иде* (Г. Гобәй); в) ризыкның тәмен белдерә: *Әни базардан* ***әче алма*** *алып кайтты. Илгиз авылда* ***төче катык*** *ашарга ярата;* г) затның эчке үзенчәлеген тәгаенләп килә: *Исән йөртмәм мин сине дөнья йөзендә,* ***тәкәббер кыз*** (Г. Гобәй). *Кичә вокзал янында йөгереп йөргән* ***шук, наян егетме*** *соң бу?* (А. Гыйләҗев); д) әйбернең төрле үзенчәлеген, күп очракта эчке сыйфатын конкретлаштыра: ***Саф һавада якты төрткеләр*** *булып йолдызлар җемелди* (Ш. Галиев). ***Салкын күзләреңнән кайнар тамчылар*** *тамар әле!* (Ш. Галиев).

Сан белән исем янәшә килгәндә дә, алар арасында төгәлләүле мөнәсәбәт хасил була. Төп сан ияртүче компонент ролендә килгәндә, ияртүче исем аша күрсәтелгән әйбернең төгәл санын тәгаенли: *Яшендәй китереп суккан бу хәбәрдән соң,* ***бер көн*** *узды,* ***ике көн*** *узды,* ***өч көн*** *дә узды шикелле...* (Ш. Галиев).

*Бер* саны исем белән төгәлләүле мөнәсәбәткә кергәндә, югарыда әйтелгәнчә, әйбернең яисә затның санын, яки аларның билгесез булуын белдерә: *Гөлшаһидә, күңелендә үтә* ***бер җиңеллек*** *һәм сафлык тоеп, урыныннан җәһәт торды, халатын киде...* (Г. Әпсәләмов). Әлеге мәгънәне аңлату өчен, *бер* саны кабатланып та килергә мөмкин: ***«Бер-бер шатлыгың*** *бармы әллә, кызым?» – дип сорады* (Г. Әпсәләмов).

Тәртип саны белән исем арасындагы төгәлләүле мөнәсәбәт тә янәшә тору чарасы ярдәмендә хасил була ала. Бу очракта әйбернең яисә затның тәртибе тәгаенләнә: *Җирдә тереклек яралганда, иңенә канат чыкканчы,* ***беренче кошлар*** *да биектән төшеп, бәрелеп харап булгандыр...* (Ш. Галиев). *Икенче* саны исә, үзенең беренчел мәгънәсен югалтып, ияртүче исем белән белдерелгән әйберне яки затны ассызыклау өчен хезмәт итә. Әлеге очракта ул *башка*, *бүтән* сүзләре белән алмаштырылырга мөмкин: *Ул* ***икенче егет*** *дигәнем староста малае икән* (Ф. Хөсни).

Әгәр ияртүче компонент парлы саннан торса, ул ияртүче исем белән бирелгән әйбернең яки затның якынча санын конкретлаштыра: *Аның тирәсендә җәңгәчәй һәм тагын* ***өч-дүрт кыз*** *чуала* (Ә. Еники).

Бүлем саны, ияртүче копонент булып килгәндә, ияртүче исем белән бирелгән әйбернең яисә затның бертигез сандагы төркемнәргә бүленүен ачыклый: *Сез миңа* ***бишәр сүз*** *языгыз* (М. Мәһдиев).

*Берәр* саны исә билгесезлек мәгънәсен белдерә: *Ниятем: болай җае туры килсә, нинди дә булса район учреждениеләренең берсенә*

*секретарьмы, хисапчымы булып эшкә урнашу; алай барып чыкмаса, ронога кереп, **берәр мәктәпкә** укытучы итеп җибәрүләрен сорау* (Ф. Хөсни).

Кайбер хәбәрлек сүзләр исем белән янәшә килсәләр, шулай ук төгәлләүле мөнәсәбәт хасил була: ***Кирәк кешеләр** килеп беттеме? Юк* хәбәрлек сүзе, исемгә ияреп, ияртүче исем белән бирелгән әйбернең яисә затның сөйләүче өчен бернинди дә әһәмияткә ия булмаганлыгын күрсәтә: *Ялгыз хатын-кызга, **юк сүзен** бар итеп, сагыз кебекябышырга йөргән ир-атларны беренче генә очратуы түгел ләбаса* (М. Мәһдиев).

Янәшә тору чарасы ярдәмендә рәвеш белән сыйфат сүз төркемнәре арасында да төгәлләүле мөнәсәбәт барлыкка килергә мөмкин. Күп очракта иярүче компонент булып күләм-чама рәвеше килә һәм ул ияртүче компонент белән белдерелгән билгенең күләмдәрәҗәсен тәгаенли: *Оппонентлар да коры рәсмилеккә **беркадәр җылы** хәерхаһлык кушып, күбрәк мактап, азрак тәнкыйтьләп, кыскасы, бөтен шартын китереп, диссертация турында үз фикерләрен әйттеләр* (Ә. Еники). *Өебез май кебек җылы, тик **бераз караңгырак*** (Ә. Еники).

Рәвеш белән икенче бер рәвеш тә үзара янәшә торып, сөйләмдә төгәлләүле мөнәсәбәт хасил була ала. Күләм-чама, саф, охшатучагыштыру рәвешләре икенче бер рәвеш белән янәшә торганда, ияртүче компонент белән күрсәтелгән билгенең күләме тәгаенләнә: *Тукран **шулкадәр тиз** вә каты такылдатты ки, кыз түзмәде, башын күтәреп карады* (М. Хәбибуллин).

Әгәр янәшә тору чарасы ярдәмендә вакыт рәвешләре арасында төгәлләүле мөнәсәбәт хасил була икән, бер вакыт иярүче компонент белән белдерелгән вакыт аша төгәлләндерелә: ***Кичә кичен** генә мунча кергәнне сылтау итеп, бүген битен дә юмаган унбиш-уналты яшьлек малайлар училище коридорында колхоз тузанын кагалар* (М. Мәһдиев).

Кайбер очракта төгәлләүле мөнәсәбәтне хасил итүдә янәшә тору чарасына ярдәмгә *-ы/-е*, *-сы/-се* тартым кушымчасы да өстәлеп килә. Бу күп очракта исемнәр арасындагы ияртүле бәйләнешкә хас. Исем белән исем янәшә килеп, ияртүче компонент тартым кушымчасын алганда, түбәндәге мәгънә төсмерләре чагылыш таба.

Ияртүче исем белән белдерелгән әйбер яки зат иярүче исем аша бирелгән билгеле әйбергә яисә затка карый. Бу очракта, иярүче компонент булып, иялек килешеннән башка да билгеле булган исемнәр кулланыла, ягъни ялгызлык исемнәр, уникаль әйбер яки күренеш исем-атамалары һәм үзен төгәлләп килә торган сүзләре булган исемнәр алына: ***Кояш нурлары** булып, күзләреңә төшәрмен, яфраклар булып муеныңа сарылырмын, җилләр булып гәүдәңә уралырмын* (Ш. Галиев).

Әгәр иярүче компонент булып уртаклык исемнәр килсә, бу төгәлләүле бәйләнештә конкрет әйбернең билгесез әйбергә мөнәсәбәте

чагыла: *Бик юка туралган,* ***борчак оны*** *катыш* ***арыш онынннан*** *иләмичә пешерелгән, уалып торган ипи килде* (А. Гыйләҗев).

Ияручә компонент тартым кушымчасын алып, ияручә белән ияртүче исемнәр янәшә торган очракта, ияручә сүз ияртүче исемне милләте ягыннан тәгаенләп килә ала: *Җан диләр, йөрәк диләр,* ***татар халкы*** *шулар уртасына Күңел дигән серле дәрья урнаштырган* (А. Гыйләҗев). *Әркәшә Пермяков –* ***рус малае*** (М. Мәһдиев).

Ияртүче исем белән белдерелгән әйбер яки зат үзенең атамасы аша төгәлләндерелә: *Безнең күңелләргә Бетховен, Шаляпин, Григлар да иркен керә, океан-диңгезләр, елга-дәрьялар,* ***Кавказ-Кырым таулары*** *да сыя, алар да синеке, син – кеше, синең күңелең күпне тели, күпне үз итә ала* (А. Гыйләҗев).

Ияртүче сүз – ыруглык, ә ияручә исем төр төшенчәсен белдергәндә, ыруглык төшенчәсе төр аша ачыклана: *Әрсез күгәрченнәр кыектан-кыекка пыр-пыр очты,* ***шомырт агачларында*** *тирбәлгән ач күз чыпчыклар чыркылдашты...* (А. Гыйләҗев).

Ияртүче компонент – өлешне, ә ияручә исем бөтенне белдергәндә, берничә мәгънә төсмерен аерып чыгарып була: а) нинди дә булса әйбергә (бөтенгә) аның кайсы да булса өлеше карый: *Дилә, тукталып, озынча, ябык бармаклары белән Идриснең* ***күлмәк якасын*** *кайтарып карады* (А. Гыйләҗев); ә) нинди дә булса бөтенгә күләме яки саны ягыннан кимрәк булган шундый ук төрдәге бөтен туры килә: *Һәм Хәлил өчен бу мәхәббәт диңгез төбеннән табылган саф* ***энҗе бөртеге*** *кебек гаҗәеп бер байлык иде, ак итә, пакь итә, яктылыкка илтә торган гомерлек бәхет иде* (Ә. Еники); б) нинди дә булса урынга аның өлеше карый: ***Ирен читләрендә*** *көнләшү сызыклары үткен пәке булып сызылып тора* (Ш. Галиев).

Шулай итеп, мисаллардан күренгәнчә, һәр очракта да өлеш бөтен аша төгәлләндерелә. Бу өлеш шул бөтен составына кергән.

Ияручә компонент ияртүче исем белән бирелгән әйбернең, күренешнең барлыкка килүендә максат булып торган әйберне белдерә, ягъни предметның ни өчен билгеләнүен аңлата, яисә әйбернең, затның урнашкан, барлыкка килгән урынын ачыклый: *Табигый ки, Бикмимер* ***балалар йортында*** *үсә, Суворов мәктәбен тәмамлагач, Казанда ук танк училищесында белем ала* (Т. Галиуллин). *Кулына ни эләксә – күмер кисәгеме, акбурмы, чыбык кисәгеме – стенага,* ***мич акшарына, урам комына, яр балчыгына,*** *ак кәгазьгә иң әүвәл кеше сурәтен сызгалый* (А. Гыйләҗев). *Шул көннәрдә Яңа елга багышланган* ***стена газетасы*** *чыкты* (М. Хәсәнов).

Әлеге мисаллардан күренгәнчә, урын мәгънәсе ияручә компонент аша белдерелә. Кайчак киресе дә була: урынны ияртүче компонент атый. Ияручә сүз бу очракта шул урын белән бәйле булган әйберне яисә затны күрсәтә: ***Картлар дөньясы*** *аерым яшәсә, моңсу була иде* (Ш. Галиев).

Ияртүче компонент вакытны белдерә, һәм ул ияручә исем аша төгәлләндерелә. Вакыт еш кына вакыт аша тәгаенләнә: ***Апрель киче***

(Ә. Еники). Вакыт иярүче сүз аша гына да белдерелә ала: ***Яз исе*** *– сафлык исе, сәбәпсез сөенеч, рәхәт үзгәрешне сиздергән хуш дулкын күңелгә кагылып үтте* (Ш. Галиев).

Янәшә тору чарасы һәм тартым кушымчасы ярдәмендә исем сүз төркемнәре үзара тәгълләүле мөнәсәбәткә кергән очракта, иярүче компонент ияртүче исем белән бирелгән әйбернең яки күренешнең составында булган әйберне белдерә: ***Каз бәлеше*** *була,* ***кабак бәлеше,*** *каздан* ***баш-аяк бәлеше*** *була* (М. Мәһдиев). *Коридор буйлап электр тогы узгандай булды, һәм без, туң миләребезне кыймылдатып өлгергәнче,* ***тузан болыты*** *эченнән ялтыравыклы күзлек пыялалары күренде* (М. Мәһдиев).

Исемнәр үзара янәшә килеп һәм ияртүчесе тартым кушымчасын алган очракта, объект белән башкаручының мөнәсәбәте дә чагыла ала. Бу вакытта объект башкаручы ягыннан тәгълләндерелә: *Тәнзилә апа үзенең нечкә генә тавышы белән Гарданов абыйны бүлдерде: «Бүреләр оясы икән», – диде* (Н. Дәүли), яисә башкаручы объект ягыннан тәгаенләнә: ***Пролетариат дошманнары*** *безгә дә, сезгә дә явызлык эшләргә чамалыйлар* (Н. Дәүли).

Исем икенче бер тартым кушымчалы исем белән янәшә килеп, тәгълләүле мөнәсәбәт хасил булган очракта, иярүче исем ияртүче сүз белән бирелгән процессны коралы яисә туры объекты аша ачыклый: ***Гражданнар сугышы*** *вакытында Колчак баскынчыкларымы, кызыл зәхмәтләрме, хәзер ул хәтлесен берәү дә әйтә алмый, этисе мулланы, күңелсез булмасын өчен абыстайны да атып китәләр* (Т. Галиуллин).

Иярүче компонент белән белдерелгән әйбер ияртүче исем аша күрсәтелгән әйбергә охшатылган булырга мөмкин: *Нәни очкынны дөрләтеп,* ***мәхәббәт уты*** *кабызмакчылар* (Ш. Галиев). *Юк, энем,* ***йөрәк ялкынын*** *кул белән капшап кына сизеп булмый, маташма* (Н. Дәүли).

Әдәби телдә һәм сөйләмдә исемнәрне охшату-чагыштыру яки сүзне көчәрелмә мәгънәдә куллану нигезендә дә тәгълләүле мөнәсәбәт хасил була: *Кеше гомере үтә кыска,* ***саескан гомерен*** *биргән дөнья адәм баласына* (А. Гыйләҗев).

Исем фигыль дә тартым кушымчасын алган исем белән янәшә торганда, тәгълләүле мөнәсәбәт барлыкка килә. Бу очракта исем белән белдерелгән әйбер яки зат үзенең процессы ярдәмендә тәгълләндерелә. Анда әйбер, зат йә башкаручы, йә булмаса объект булып килә: *Ләкин аңарда* ***яшәү теләге*** *үлемнән көчлерәк була* (Г. Гобәй). *Әхәтнең кайчандыр әйткән* ***кисәтү сүзләре*** *хәтергә төште* (А. Гыйләҗев).

Югарыдагы мисаллардан күренгәнчә, янәшә тору чарасы сүзләрнең лексик мәгънәсе һәм интонация ярдәмендә исем белән фигыль, сан белән фигыль, рәвеш белән фигыль, исем белән исем, сыйфат белән исем, рәвеш белән исем, хәбәрлек сүз белән исем, рәвеш белән сыйфат һәм рәвеш белән икенче бер рәвеш арасында тәгълләүле

мөнәсәбәт хасил итә ала икән. Ияртүче сүзгә тартым кушымчасы өстәлсә, төгәлләүле мөнәсәбәт ике исем сүз төркеме һәм исем фигыль белән исем арасында барлыкка килә.

**Әдәбият һәм чыганаклар**

*Алпаров Г.* Сайланма хезмәтләр: Грамматикасы һәм гомуми тел белеме мәсьәләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1945. 330 б.

*Әпсәләмов Г.* Ак чәчәкләр: Роман. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 510 б.

*Галиев Ш.* Илһамым-мәхәббәтем: лирик язмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 408 б.

*Галиуллин Т.* Дәгъва: Хикәяләр, публицистика, әдәби тәнкыйть. Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. 256 б.

*Гобәй Г.* Маякчы кызы: Повесть. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 191 б.

*Гыйләҗев А.* Әсәрләр: дүрт томда. 4 т.: Роман. Повесть. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. 400 б.

*Дәүли Н.* Яшәү белән үлем арасында: Повесть. Җимерелгән бастион: Роман. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. 446 б.

*Еники Ә.* Җиз кыңгырау: Хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. 224 б.

*Зәкиев М.З.* Хәзерге татар әдәби теле: Синтаксис. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1958. 244 б.

*Зөлкарнәев Л.* Кар өстендә алмалар: Шигырьләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 79 б.

*Мәһдиев М.* Сайланма әсәрләр: 3 томда. 1 т.: Повестьлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. 534 б.

*Сафиуллина Ф.С., Ибраһимов С.М.* Татар теле: Синтаксис. Казан: Мәгариф, 1994. 176 б.

*Сагдиева Р.К.* Аффиксы как средства выражения кокретизирующих отношений в татарском языке: дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2000. 164 с.

*Хәбибуллин М.* Илчегә үлем юк: Роман. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. 384 б.

*Хәсәнов М.* Саф җилләр: Роман-дилогия. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 423 б.

*Хөсни Ф.* Утызынчы ел: Роман. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. 391 б.

***Сәгъдиева Рамилә Камил кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты*
*Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты*
*Г. Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбенең*
*татар теле белеме кафедрасы доценты*